БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» 12 2025 ел № 348

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясындагы 3.2 пунктының дүртенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. 1. Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең кушымтада бирелә торган баш администраторлары исемлеген расларга.

2. Әлеге карар 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чоры бюджетыннан башлап, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2024 елның 17 декабрендәге 304номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Финанс-бюджет палатасы Рәисенә йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов